**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 151** **28 ноябрь 2024 ел.**

**“Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” 2018 елның 23 апрелендәге 122 номерлы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2018 елның 23 апрелендәге 122 номерлы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының “Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” карарына (23.05.2018 № 126, 26.11.2018 №150, 07.12.2018 №155, 22.09.2020 № 5, 30.12.2021 № 47, 30.09.2022 № 75, 02.03.2023 № 95, 24.06.2024 № 135 Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә:

2.2 пунктта «13 323 сум» сүзен «13 990 сум” сүзе белән алыштырырга;

2.14 пунктта «13 323 сум» сүзен «13 990 сум” сүзе белән алыштырырга;

1.2. Әлеге карар белән расланган “Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы

депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында" нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кадер авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19 173 |

2. Карарны Кадер авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Кадер авыл җирлеге Советы Рәисе** **Л.Н. Барсукова**